**БЕЗҺӘРВАКЫТ БЕРГӘ!..**

**БҮГЕНГЕ НОМЕРДА:** **“Мәктәп яңалыклары” (2нче бит)**

**“Балалар иҗаты” (3нче бит)**



# ЯШЬЛӘР КАЛАСЫ

Тираж 25 экземпляр

№1
16нчы
Ноябрь
Шимбә

**Балалар һәм яшьүсмерләр гәҗите** ★ **http://vkontakte.ru/club30613368**

## ЯҢАЛЫКЛАР

23нче октябрь көнне зур классларда ”Уңыш бәйрәме” булды. Көз сылуы “Сөмбелә”не каршы алдык. Ул безгә кызыклы уеннар табышмаклар, мәкальләр алып килгән. 3 команда арасында ярышлар узды һәм җиңүчеләр билгеләнде.

29нчы октябрь көнне башлангыч классларда “Уңыш бәйрәме” үтте. Бәйрәмне 2нче класс укучылары-укытучылары Хәсәнова З.Ф. җитәкчелегендә үткәрелде. Ә 1нче һәм 3нче класс укучылары “Кәҗә кергән бакчага” исемле экият күрсәттеләр (җитәкчеләре Саниева М.В.). Бәйрәм төрле уеннар белән җанланды. Әти-әниләр белән чәй эчү оештырылды.





## БУ БИК КЫЗЫК

Чыпчык ике тәүлектән артык ач тора алмый. Чөнки ул гел хәрәкәттә, тән температурасы 40 градустан югары, май катламы юк диярлек, ә үзе күп энергия сарыф итә. Шуңа аңа кышын авырга туры килә.

Иң коры урын – Чилидагы Атакама чүле. Бу чүлнең кайбер районнары яңгыны 1570 елдан 1971 елга кадәр, 400 елдан артык күрмәгән. Урыны-урыны белән бөтенләй яңгыр яуганы юк.

Дөньяда иң киң таралган исем – Мөхәммәд.

Көнбатыш Кытайда чәйгә шикәр түгел, ә тоз салалар.

Зәңгәр күзле кешеләр караңгыда яхшырак күрә.

Италиянең Верона шәһәрендә XIV гасыр урталарында төзелгән Кастельвеккио замогы бар. Кызыл кирпечтән ясалган диварда “М” бизәкләре төзелеп киткән. Аны тарихчылар “карлыгач койрыгы” дип тә атыйлар. Мәскәү Кремле диварлары очында шулай ук “М” тамгасы бар. Әлеге ике крепость арасындагы охшашлык бик җиңел аңлатыла. Кастельвеккио крепостен – XIV, Мәскәү Кремлен XV гасырда Милан архитекторлары төзегән.

*Интернет ресурсларыннан алынды.*

## САННАР

Эверест тавы ел саен 4 мм га үсә бара.

Планетадагы иң зур чүл – Сахара. Мәйданы 9 млн. кв.м. Чүлнең ¼ өлешен таш каплаган.

Планетадагы иң эссе урын – Ливия чүле. Монда температура +58 градус.

Кеше 1 елга 10 миллион тапкыр күз йомып ала.

Уртача кеше бер көндә 18 мең адым ясый.

Россия белән Аляска ярымутравы арасы 4 км гына.

Һавада очу буенча Африка тәвә кошы чемпион. Ул сәгатенә 72 км тизлек белән оча.

Йөзү буенча парусчы балык чемпион: кыска дистанциядә уртача 109 км/сәг тизлек белән йөзә.

Суга чуму буенча рекордны тиреле ташбака куя, ул 1200 м тирәнлеккә чума ала.

Биеклеккә сикерү буенча рекордны песи борчасы куя. Ул 34 метрга, ягъни үзеннән 130 мәртәбә биегрәк сикерә белә.

*Интернет ресурсларыннан алынды.*

# Мәктәп яңалыклары

Иң күп бишле алучылар:



*Сәйфетдинов Ранил – 8 бишле*



*Саниев Айнур – 8 бишле*

**Икеле алучылар:** Вәлиева Рания,Хисматов Илсаф, Хәертдинов Алмаз, Хөҗҗәтов Фәнис, Сөнәгәтов Камил, Сөнәгәтов Шамил, Шәйдуллин Булат.

**Соңга калучылар:**

**Пәнҗешәмбе:** соңга калучылар булмады.

**Сишәмбе:** Сагдиева Лилиана, Гөмәрова Гөлзирә, Ямаева Зарина, Давлетшин Илдан, Давлетшина Диана.

**Чәршәмбе:** Шәмсетдинов Ильяс, Ямаева Зарина, Гатиятова Чулпан, Гатиятов Рамил, Гөмәрова Гөлзирә, Сагдиева Лилиана.

**Пәнҗешәмбе:** Хисматов Илсаф, Гөмәрова Гөлзирә, Сагдиева Лилиана.

**Җомга:** Давлетшина Диана, Ямаева Зарина, Давлетшин Илдан, Гөмәрова Гөлзирә, Сагдиева Лилиана.

**Шимбә:** Гөмәрова Гөлзирә, Сагдиева Лилиана, Ямаева Зарина, Давлетшина Диана, Гатиятов Рамил.

*Мансур Төхбатуллин,*
*Уку секторы*

# БАЛАЛАР ИЖАТЫ

## Умартачылар.

Минем әниемнең әтисе, Рәис бабам, яшь вакытта умарталыкта умартачы ярдәмчесе булып эшләгән. Бу хәл 1979нчы елның җәендә, умарта кортлары күч аерган вакытта, була. Рәис бабам, Нәзирә әбиемнең әтисе, Нәзир бабам белән умарта карыйлар. Шул вакытта бер умартадан бал кортлары күп итеп очып чыга башлый. Ул вакытта әле бабам күчләрне читкә җибәрми торган дарулар кулланмый торган була. Шуңа, бабам, озын колгага беркетелгән күч тоткычны күтәреп әрле – бирле йөри башлый. Күч умарталык өстендә очып йөри, ләкин утырырга, ошаган урын таба алмый. Инде, бабам да арый, колганны күтәреп йөреп. Шул вакыт кызык хәл була. Күч бабам күтәргән колганны урап ача да, бабамның башына төшеп утыра, ярый әле, ул кортлардан саклану өчен битлек кигән була. Умарта күче, шулай итеп, Рәис бабамның башына әкеренләп утырып бетә. Нәзир бабай тизрәк бал кортларын махсус тубалга күчерә. Бабамны бер коррта чакмый,чөнки ул алардан курыкмаган.

*Лилиана Сагдиева*

## Көзгә багышланган рәсемнәр



Илүзә Хөҗҗәтова



Гөлназ Хәертдинова



Фәнис Хөҗҗәтов



Рания Вәлиева

*Илүзә Хөҗҗәтова, “Балалар иҗаты” бүлеге*

# Реклама




# БЕЛДЕРҮЛӘР

Белдерүегезне “Яшьләр каласы” гәҗитендә күрәсегез килсә, 42743 телефоны буенча яздырып калдыра аласыз.

Басылды: филиал МБОУ “СОШ с. Сарлы” – “ООШ с. В. Стярле” 25 экземпляр Телефон: 8 (85592) 42743

ЯШЬЛӘР КАЛАСЫ

**Баш редактор**
**Миләүшә Хәертдинова**

**Редакция адресы:** 423314, ТР, Азнакай районы, Югары Стәрле авылы, Совет урамы, 38 Б, инглиз теле кабинеты, “Яшьләр каласы” гәҗите редакциясе. http://vkontakte.ru/club30613368

Гәҗит аена бер тапкыр чыга, сату хакы – килешү буенча.

**Баш редактор ярдәмчесе:** Л. Сәгытдинова
**Менеджер:** И.Солтанов
**Фотограф**: К.Сөнәгәтов
**Рәссам:** Г.Мөшәрәпова
**Уку секторы:** М.Төхбатуллин
**Бәйрәмнәр бүлеге:** Г. Гомәрова
**Реклама бүлеге:** Р.Сәйфетдинов
**Кызыклы мәгълүмәт:** Л. Сагдиева
**Балалар иҗаты:** И.Хөҗҗәтова
**Учредитель:** Г.И. Зиганшина